**Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгының**
**2022 нче елдагыэшчәнлеге турында хисабы.**

Хөрмәтле Вадим Ильич, хөрмәтле президиум,
авылдашлар һәм чакырылган затлар!

**Слайд 1.** Менә тагын бер ел узып, еллык эшчәнлеккә нәтиҗә ясар вакыт җитте. Бүгенге җыелыш - җирлек Уставын үтәү, анда җирлек башлыгы тарафыннан башкарылган эшләр турында халык алдында хисап тоту, киләчәккә планлаштыру буенча эш алып бару бурычы билгеләнгән. Җыелышның максаты - Кибәк Иле авыл җирлегенең 2022 елда социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2023 елга бурычлары турында халыкка җиткерү, яшәешне тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре буенча фикер алышу.

Авыл җирлеге үзенең эшчәнлеген "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы" 131 нче номерлы Федераль Законга Һәм авыл җирлеге Уставына нигезләнеп алып бара.

Безнең төп бурыч – халыкка хезмәт күрсәтү, тыныч, куркынычсыз тормыш итүне тәэмин итү, авылда яшәүчеләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту, авылларның социальйөзен үзгәртү, халыкның активлыгын арттыру. Шушы мәсьәләләрне хәл итүдә җирлектә төрле оешмалар эшләп килә: мәгариф, мәдәният, халык куллану товарлары сату, халыкка беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча фельдшер-акушерлык пункты, халыкка хезмәт курсәтүче учреждениеларның эшен контрольдә тоту.

Ә хәзер сезне 2023 елның 1 гыйнварына Кибәк Иле авыл җирлеге территориясенең төп статистик мәгълүматлары белән таныштырып китәм.

**Слайд 2. Статистик мәгълүмат:** Кибәк Иле авыл жирлеге территориясе барлыгы 39,6 кв.км мәйданны биләп тора. Авыл территориясендәге юлларның озынлыгы 10 км тәшкил итә. Барлык хуҗалык саны - 98, шул исәптән җирле хуҗалыклар саны - 79.

**Слайд 3.** Халык саны - 2023 нче елның 1 гыйнварына 188 кеше рәсми рәвештә теркәлгән. Территориядә яшәүче халыкның 54,5% (107 кеше) эшкә яраклы, шулардан 95 кеше төрле өлкәдә эшлиләр, вакытлыча эшләмәүчеләр саны 8 (7,1 %) кеше. Бүгенгесе көндә авыл җирлегендә яшәүчеләрдән 12 кеше эш белән үзебезнең җирлектә тәэмин ителгән, бу хезмәткә яраклыларның 11 % тәшкил итә. Авыл җирлегендә эш урыннары булмау сәбәпле калган 80 (73,4%) кеше читкә чыгып эшләргә мәҗбүр, авыл җирлегеннән читтә 34 кеше, район җирлегеннән читтә 44 кеше эшли.

**Слайд 4.** Пенсионерлар саны – 54, шул исәптән 1-2 группа инвалидлар 7 кеше, 3 группа инвалидлар 3 кеше, пенсия яшенә житмәгән 6 инвалид бар.

14 гаиләдә 18 яшькә кадәр 30 бала тәрбияләнә, 3 һәм аннан күбрәк балалы 4 гаилә, 3 ялгыз ана, 2 тулы булмаган гаилә 2 бала тәрбияләп үстерә. 16 яшькә кадәр балалар саны 28.

Демографик ситуациягә килгәндә, җирлегебездә халык саны кызганычка каршы, кимү ягында. Моңа сәбәпче булып туучылар саны кимү, үлем очраклары арту, шулай ук җирлектән күчеп китү тора. 2022 елда авыл җирлеге территориясендәге демографик хәлгә килгәндә, саннар сөенерлек түгел.

Җирлектә 3 кеше якты дөньядан китеп барды.

**Слайд 5. Шәхси ярдәмче хуҗалык:** Авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалыклар аерым урын алып тора, алар халыкны азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү мөмкинлеге бирә, гаиләнең керем өлеше дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итә, сыйфатлы азык-төлек базары ассортиментын киңәйтә. Бүгенге көндә җирлектәге 99 хуҗалыкның 79 хуҗалык терлек асрый, шәхси ихтыяҗлар өчен сөт һәм ит җитештерә. 2023 елның беренче гыйнварына 107 баш мөгезле эре терлек бар, шулардан 3 баш сыер, сарык-кәҗәләр 82баш , 715 баш кош-корт , 49 баш умарта .

**Слайд 6.** Республика берничә ел рәттән терлек азыгы сатып алу өчен сыер һәм кәҗә асраучы хуҗалыкларга субсидия бүлеп бирә. 2022 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәр савым сыерга 2300 сум һәм савым кәҗәгә500 сум исәбеннән субсидияләр бүлеп бирелде. Шәхси хуҗалыклар барлыгы 5600 сум күләмендә субсидия алдылар.

**Слайд 7. Пай җирләренә аренда түләве**: Кибәк Иле авылында яшәүче гражданнарның үзләренең милке булып торган пай җирләрен килешү нигезендә «Ак Барс Питрәч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана. Ул 2022 елга пай җире өчен аренда түләвен акчалата түләде.Бүгенгесе көнгә пайчылар белән исәп-хисап ясалып бетте.

Җаваплылыгы чикләнгән "Ак Барс Питрәч" оешмасы өлкәннәр көнен игътибарсыз калдырмады, 62 пенсионерга 400әр сумлык ашамлыклар җыелмасы тапшырылды. Моның өчен җаваплылыгы чикләнгән"Ак Барс Питрәч" җәмгыяте директоры Зиннатов Радик Асхатовичка барлык өлкәннәребез исеменнән рәхмәтемне җиткерәм.

**Слайд 8. Җитештерү:** Авыл җирлеге территориясендә 1 шәхси эшмәкәр пилмән һәм ярымфабрикатлар җитештерү белән шөгыльләнә**.** Барлыгы 8 кеше эш белән тәэмин ителгән. Җитештергән продукцияне заказ буенча район территориясендәге һәм Казан шәһәрендәге кибетләргә тапшыралар.

**Слайд 9.** "Альтаир" таваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры Абдрахманов Раил Фаил улы. Бөртеклеләр эшкәртү белән шөгыльләнәләр,чит илләр белән сәүдә итәләр. Киләчәктә 12 кешене эш белән тәэмин итәргә планлаштыралар.

**Слайд 10.** ИП "Иванов.А." җиләк-җимеш агачлар үстерү белән шөгелләнәләр. Киләчәктә теплица төзергә планлаштыралар һәм 5 кешене эш белән тәймин итәчәкләр.

**Слайд 11.** Үзмәшгуль Шакиров Илшат Таһир улы. Казлар үстерү белән шөгелләнәләр, киләчәктә 3 кешене эш белән тәэмин итергә планлаштыралар.

**Слайд 12. Бюджет:** Башкарма хакимиятнең төп бурычларыннан берсе – бюджет акчаларын вакытында һәм дөрес итеп файдалану.

2022 нче елда авыл җирлеге бюджетының үз керемнәре фаразы социаль-икътисади үсешенең төп күрсәткечләреннән, салым һәм салым булмаган керемнәр керүдән чыгып исәпләнгән иде.

2022 нче елда безнең муниципаль берәмлек бюджетының керем өлеше 2 миллион 69 мең 300 сум күләмендә билгеләнгән. Ел дәвамында 2 миллион 51 мең 800 сум керем кергән.

Бюджетның керем өлешенең төп чыганаклары:

- Физик затлар кеременә салым – 14,3 мең сум каралган, үтәлеш – 14,5 мең сум, җир салымы – 85 мең сум каралган, үтәлеш – 99,3 мең сум, физик затлар милкенә салым–29,0 мең сум каралган, үтәлеш 26,0 мең сум .

2022 нче елда җирлек бюджеты керемнәрендә шулай ук район һәм республика бюджетларыннан 1 миллион 862 мең 400 сум күләмендә түләүсез керемнәр дә исәпкә алынган. Бюджетның керем өлеше буенча үтәлеш 1 миллион 818 мең сум тәшкил итте.

Бюджет чыгымнары 2 миллион 039 мең 400 сум тәшкил итте. Чыгым өлеше буенча үтәлеш92%. Җирлек территориясендә башка бюджет оешмалары да эшли,болар:

- Кибәк Иле авыл мәдәният йорты: бюджет – 1205,6 мең сум;
- Кибәк Иле авылы китапханәсе: бюджет – 345,8 мең сум,
- Барлыгы 1567,8 мең сум.

**Слайд 13. Үзара салым:** 2021 елның 28 нче ноябрендә булып узган узара салым кертү һәм аны куллану буенча халык җыенында кабул ителгән карар нигезендә бер сайлаучыга 1000 сум күләмендә салым җыю каралган иде. Авыл җирлеге буенча 145меңсум акча җыелды. Республика бюджетыннан 580 мең сум акча керде. Барлыгы 725 мең 000 сум акча җыелды.Җыелган үзара салым акчасына зираты территориясен төзекләндерелде.

**Слайд 14.** 2022 нче елның 22 октябрендә 2022 елда үзара салым кертү һәм аны куллану буенча халык җыены уздырылды. Җыен нәтиҗәсе буенча 2022 нче елда да.............. (500 рублей на строительство дет.площадки). Республикадан үзара салым акчалары өчен мөмкин кадәр күбрәк финанс алыр өчен безгә 20 нче марттан да соңга калмыйча үзара салым акчаларын банкка тапшырырга кирәк. Республикабыз мондый мөмкинчелек биргәндә файдаланып калырга кирәк дип уйлыйм. Бу эшләрне без Республика ярдәменнән башка берничек тә башкарып чыга алмыйбыз. Нәрсә генә эшләсәк тә авыл җирлеге өчен эшләнә.

**Слайд 15. Төзекләндерү:** Авыл җирлеге территориясендә ел дәвамында төзекләндерү эшләре алып барыла. Ел дәвамында авылыбыз зиратын чистарту өмәләре оештырылды, корыган агачлар кисеп чыгарылды, юл кырыйларында һәм авыл эчендә чүп үләннәре чабылды. Авыл зираты территориясенә кирәк-яраклар өчен сарай төзелде. Бу эшне башлап йөрүче Хуҗиахмәтов Айдар Минзакировичка һәм аның ярдәмчеләренә зур рәхмәтебезне белдерәбез.Шулай ук барлык спонсорларыбызга да рәхмәт белдерәбез. Авыл халкы ярдәме белән чишмәбез төзекләндерелде. Санитар-экологик икеайлык кысаларында авыл җирлеге территориясен чистарту буенча өмәләр оештырылды. Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбыз истәлегенә куелган һәйкәлгә ремонт

ясалды.Авыл җирлеген төзекләндерүдә битараф булмаган, актив катнашкан барлык авыл халкына рәхмәт җиткерәм.

**Слайд 16. Китапханә**: Кибәк Иле авылы китапханәсендә барлыгы 5133 экземпляр китап исәпләнә. Бу исемлек быел тагын 246 экземпляркитап белән тулыландырылды.Ел дәвамында төрле конкурслар, викториналар, квест-уеннар оештырыла, район күләмендә үткәрелә торган чараларда актив катнашалар,авыл җирлегендә башкарыла торган эшләрнең берсеннән дә читтә калмый.

**Слайд 17. Мәдәният**: Кибәк Иле авыл җирлегендә бүгенгесе көндә 1 мәдәният йорты эшләп килә. Мәдәният йорты хезмәткәрләре авыл җирлегендә башкарыла торган эшләрнең берсеннән дә читтә калмыйлар. Авыл үзешчәннәре белән бергәләп концертлар, спектакльләр куялар. Район һәм республика күләмендә оештырылган чараларда актив катнашалар.

**Слайд 18.** Халык белән эшләү рәвешләре төрле: бу тематик кичәләр, концертлар, халык күңел ачулары, уен программалары, конкурслар, викториналар, шулай ук спорт чаралары. Мәдәният йорты базасында “АСЫЛЪЯР” вокаль ансамбле үз эшчәнлеген тормышка ашыра. 7 төрле түгәрәк эшләп килә һәм барлыгы 87 кешене берләштерә. 2022 нче елда барлыгы 117 төрле чара үткәрелде.

**Слайд 19. ФАП**: 1 апрельдән ФАП эшли башлады.

**Слайд 20. Мәчет:** Авыл халкының рухи байлыгын баетуда авыл мәчетенең роле зур. Мәчеткә җомга намазларына 5-6 кеше йөри. Теләге булган кешегә гарәп теле укыту, намазга өйрәтү эшләре оештырылган. Мәчет бинасы газ белән җылытыла. Су кергән. Коммуналь хезмәтләр өчен үз вакытында түләнеп бара.

**Слайд 21. Кибет:** Шәхси эшмәкәрнең бер кибете авыл җирлеге халкын көнкүреш товарлары белән тәэмин итеп тора. Моннан тыш атнага бер тапкыр район үзәгеннән күчмә кибет килеп халыкка хезмәт күрсәтә. Атнага 3 тапкыр яңа пешкән икмәк, күмәч килеп тора. Еллык товар әйләнеше 11,72млн.сум тәшкил итеп, бер кешегә күчереп исәпләгәндә 58610 сум туры килә.

**Слайд 22. Совет эшчәнлеге:** Кибәк Иле авыл җирлегенең вәкиллекле органы 7 депутаттан тора. Җирлек Советы үз эшен 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131 нче номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы, җирлек уставы нигезендә алып бара. Авыл җирлеге органы үзенең эшен 2022 нче елга расланган эш планы һәм югары оешмалардан килгән күрсәтмәләр буенча алып барды. Үткән ел барлыгы 3 халык җыелышы һәм авыл жирлеге Советының 8 утырышында җирлек эшчәнлегенә кагылышлы 10 мәсьәлә каралып, тикшерелгән мәсьәләләр буенча тиешле норматив-хокукый актлар кабул ителде.Җирле үзидарә турындагы федераль һәм республика законнарына таянып, авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелде.

Авыл җирлеге   Советы үзенең төп эшчәнлеге: җирлек территориясендә яшәүче халык мәнфәгатьләрен, аның үтенеч-сорауларын уңай хәл итү өстендә эшли.

2022 елда төрле йомыш-үтенеч белән  9 кеше мөрәҗәгать иткән, барлык мөрәҗәгатьләр дә уңай хәл ителгән. Нигездә халыкны элемтә, яктырту, коммуналь хуҗалык белән бәйле мәсьәләләр кызыксындыра. Безнең вәкаләттә булмаганнарын районның төрле оешмаларына чыгып уңай хәл итәргә тырышабыз.

**2022 нче елның 16 нчы гыйнварында үткән халык җыенында әйтелгән сорауларның булмадэ???:**

**2023 нче елга планнар:**

- Үзара салым акчасына авылда балалар мәйданчыгы төзү;
- Авыл территориясен төзекләндерү буенча өмәләр оештыру;

**Слайд 23.** Хөрмәтле авылдашлар!

Без сезнең белән планлаштырылган барлык чараларны да лаеклы рәвештә үткәрә алырбыз дип ышанып калам.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә, авыл җирлеге Советы халыкның тормыш көнкүрешен яхшырту буенча билгеләнгән планнарны хәл итү өчен бөтен көчен куячак.

Чыгышым тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.